ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

13 апрель 2021 ел — Яңа Чыршылы — № 5

**Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымтада бирелгән Административ регламентын расларга.
2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 октябрендәге 21 номерлы карарының 1 пунктындагы 3 нче абзацын үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы авылы, Заречная, 25, Үзәк урамы 12А йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы — Р.Ә. Мөхәмәтшина